


АК ШӘҺӘРДӘ

Иртән торсам, күңел тулы дулкын
Урамнардан кырга үрелә.
Ак шәһәрдә әллә яшәгәнгә,
Йөрәкләрдә якты көн генә.

Текә ярлар бергә тоташалар,
Ярны узып елга йөгерә.
Киләчәккә салган күпер аша
Юллар ачык хыял җиренә.

Көләч күзләр, көләч йөзләр балкый,
Ак таш булып хыял үрелә.
Тар коймасын сүтеп халкым бүген
Иркен тормыш төзи үзенә.

Язмышымны, юлым, уртак иттең,
Яшьлегем дә КамАЗ бер генә.
Шатлыгымны алып юлга чыгам,
Машиналар килә илемә.

**Фирая Хәлиуллина.**

**Ак шәһәрдә**

Иртән торсам,күңел тулы дулкын

Урамнардан кырга үрелә.

Ак шәһәрдә әллә яшәгәнгә,

Йөрәкләрдә якты көн генә.

Текә ярлар бергә тоташалар,

Ярны узып елга йөгерә.

Киләчәккә салган күпер аша

Юллар ачык хыял җиренә.

Көләч күзләр, көләч йөзләр балкый,

Ак таш булып хыял үрелә.

Тар коймасын сүтеп халкым бүген

Иркен тормыш төзи үзенә.

Язмышымны, юлым, уртак иттең,

Яшьлегем дә КамАЗ бер генә.

Шатлыгымны алып юлга чыгам,

Машиналар килә илемә.